Муниципальное бюджетное учреждение культуры «Бардымская централизованная библиотечная система»

# БАРДА ЯГЫ СӨЙЛӘКЛӘРЕ, РИВАЯТЬЛӘРЕ ҺӘМ МИФЛАР

## Были, легенды и мифы Бардымского района, рассказанные старожилами района. 2013- 2014 годы

Барда 2014

## “Бәке чишмәсе”

Тол елгасының уң як ярында тау тезмәләре тезелеп киткән. Шуларның берсе Усаклы тау, таудан югары күтәрелүгә тигезлек башлана. Шул тигезлекләрне ныклап карасаң таллыклы урыннарны күрергә мөмкин. Бу суның өскә якын урнашуын күрсәтә. Шуңа күрә дә бу урынны “Эчмәк” дип атаганнар, тип-тигез урында трактор бата да кала иде. Бик электән шул җирләрне Бәке әби эшкәрткән һәм аның үз чишмәсе дә булган, аңа “Бәке чишмә” дип исем кушканнар. Ул үзе зур каен төбендә башлана да 2-3 м. ага да югала, җир астына төшеп кача. Бәке әбидән соң чишмәне Газиз, аннан улы Нургали, аннан Габдрафикъ, ә хәзер Алмаз һәм Инсаф карыйлар. Чишмә ят кешене кабул итми. Чиста, рәт белгән кешене генә кабул итә. Анда зур казан куелды, өсте ябык, ә кабыргадан улак буенча су ага да югала. Яңгыр яумаганда Габдрафикъ еш кына Бәке чишмәгә яңгыр сорап чыга иде, кызык бит, туры килә торган иде. Пока әле малайларны тыңламый, димәк ыраешы җитми дигән сүз.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## “Родник Баки”

На правом берегу реки Тулвы выстроилась горная гряда. Среди гор - гора Усаклы (Осиновая), после подъема на гору начинается равнина. Если повнимательнее приглядеться к этой равнине, можно заметить заросли ивы, это говорит о том, что неглубоко вода. Поэтому это место называли “Эчмак” (местн.- покрывало, которое подкладывали под новорожденного). Здесь, на ровном месте, часто застревали трактора. В давние времена эти земли обрабатывала Баки аби, у нее был свой родник, этот родник стали называть родником бабушки Баки. Родник начинается возле большой березы, течет 2-3 метра и теряется под землей. После бабушки Баки за родником ухаживали Газиз, потом его сын Нургали. Затем Габдрафик, а сейчас приглядывают Алмаз и Инсаф. Родник чужих не принимает. Принимает только чистых, порядочных людей. Там установлен большой казан, сверху закрыто, а с краю по желобу течет вода и прячется под землю. В засуху нередко Габдрафик обращался к роднику с просьбой о дожде. Что удивительно, помогало. Сыновей родник пока не слушается, видимо не хватает силы заклинаний.

Масагутова Гульзихан Газихановна, д.Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

## «Бичура»

Күршедә Мәдәхи әбиләр тора. Авыл кешеләре сөйли торган иде: “ Мәдәхинең өендә кечкенә генә солдаты бар имеш”,- дип. Гражданнар сугышы вакытында аларның йортлары урынында бик күп солдатлар үтерелгән диләр. Шул солдатларның каннарыннан Бичура – солдат калган имеш диләр. Кеше аларга керде исә, Бичура яратмаган кешесенә

әйбер белән ыргыта диләр. Без бер көн шул әбидән үлчәнерге бизмән алып тордык. Бизмәнне алган көнне чыгарып бирә алмадык бит инде. Шул төндә ишек төбендә эленеп торган безмән чулпы чылтырагандай чылтырый башлады. Куркуга төштек. Әни безне тирги башлады. Сарыкланып шул бизмәнне чыгармадагыз да, әнә Мәдәхинең солдаты кергән ди. Әни иртә белән укына-укына бизмәнне алып чыгып бирде инде. Әбинең нәрсәсен алсалар да 2-3 көн бирмәсәләр Бичурасы кереп шалтырата икән.

Язучы – Күчтәнти авылы ветеран- укытучы Гузаирова Фәния Нәҗмехәмәт кызы. 85 яшь.2013 ел.

**Домовой**

У нас по- соседству жила бабушка Мадахи. Сельчане поговаривали, что в ее доме живет маленький солдатик. В годы гражданской войны на месте ее дома было убито много солдат, и из крови этих солдат остался домовой – маленький солдатик. Когда в дом заходил человек, который ему не нравился, домовой кидал в него вещами.

Как-то раз мы взяли у старушки безмен для взвешивания. В тот же день вернуть его не успели. Ночью, висевший возле двери безмен, начал звенеть, как монеты на накоснике. Мы испугались. Мама стала нас ругать: “Озорники, вовремя не отнесли безмен, вот и пришел к нам домовой - солдатик бабушки Мадахи”. С утра, читая молитвы, мама вернула безмен хозяйке.

Оказывается , если кто-то брал у бабушки какую-либо вещь и в течение двух-трех дней ее не возвращал, домовой начинал напоминать об этом своим звоном.

Написала ветеран-педагог из д.Константиновка Гузаирова Фания Назмухаматовна, 85 лет.2013 г.

**Бичура**

Мин кияуга чыккач, 1947 елда безне әниләр башка яшәргә чыгардылар. Безнең өстәл юк. Күршедә генә Сәбехи әбиләр яши иде. Аларның өйләрендә бичуралары бар дип ишетеп белә идем мин.

Без ирем белән шул әбидән өстәл алып утырттык. Төн җитте. Йоклап кына киткән идек, теге өстәл әйтерсең биеп утыра. Шыгыр-шыгыр шыгырдый башлады. Куркып уяндык инде. Ирем өстәлгә сугып та карый. Шул хәл төн саен кабатлана башлады. Теге бичура искә төште. Төн уртасында бичура килгәнен аңладык. Һәм өстәлне Сәбәхи әбигә кире илтеп бирдек. Бул хәл шуннан соң кабатланмады.

Күчтәнти авылы ветеран- укытучы Гузаирова Фәния Нәҗмехәмәт кызы сүзеннән ( 85 яшь) Сараш китапханәче Тимганова Кадрия язып алды . 2013 ел.

.

## Домовой

Когда я вышла замуж, в 1947 году родители отселили нас жить отдельно. Стола у нас нет. По-поседству жила бабушка Сабахи. Мы с мужем слышали, что в ее доме есть домовой.

Мы взяли из этого дома стол. Наступила ночь. Только заснули, как слышим: стол словно пляшет “скрип-скрип”. Сон прошел, муж пробовал постучать по столу – бесполезно. Это повторялось каждую ночь. Вспомнили про домового. Поняли,что ночью он приходит к нам. Стол вернули бабушке Сабахи и после этого все прекратилось.

Со слов Гузаировой Фании Назмухамматовны (85 лет.) записала библиотекарь Сарашевской библиотеки Тимганова Кадрия. 2013 г.

## “Гыйльман чыпчык”

Султанай биек-биек Урал тау итәгендә урнашкан. “Шах арадан” 1,5 чакрым чамасы ераклыкта “Чыпчык” тавы сузылып ята, аны “Гыйльман чыпчык” дип тә йөртәләр. 1917 нче елда Султанайга Колчак килеп кергәч күп кенә семьядан ирләрне үзләре белән көчләп алып киткән. Шуңа күрә аның сугышчыларын чабаталы аклар дип йөрткәннәр. Авылдан латыш укчылары чабаталы акларны куганда султанайлылар урманга качканнар, араларында яралы Гыйльман да булган. Таң алдыннан Җамалетдин һәм Нурулла Ягафаровлар мәчет манарасына менеп авылдашларының төтен күтәрелүе буенча кайда ятканнарын күреп, “Чыпчыкка” баралар һәм авылдашларына бирелергә, ә коралларын Осага илтеп тапшырырга кушалар. Яралы Гыйльман үлгән һәм шунда күмелеп калган. Шуңа бу урын “Гыйльман чыпчык” та дип йөртелә.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## “Гильман чыпчык”

(гора названа в честь похоронненого на ней султанаевца)

Султанай расположен у подножья гряды высоких Уральских гор. На расстоянии полутора километров от “Шах ара” растянулась гора “Чыпчык”, еще ее называют “Гильман чыпчык”. В 1917 году, когда в Султанай вошли колчаковские войска, из многих семей мужчин они силой забрали с собой. Поэтому этих вояк называли “белые лапотники”. Когда латышские стрелки погнали из села “белых лапотников”, султанаевцы спрятались в лесу. Среди них был и раненый Гильман. Поутру, взобравшись на минарет, Ямалтдин и Нурулла Ягафаровы, по поднимающемуся дыму определили местонахождение сельчан, отправились на гору “Чыпчык” и предложили им сдаться, а

оружие сдать в Осе. Раненый Гильман умер и был похоронен на этой горе. Поэтому это место и называют “Гильман чыпчык”.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

**“Елак малай”**

Күчтәнти авылы белән Амировка арасында ике елга үтә, Чәпчелде һәм Сакаткы. Сакаткыны кискен борылып тауга күтәрелә башлауга (Амировкага барганда) уң якта куе агачлык, а сул якта басу җәелеп ята. Куе урманлык инде бик карт, агачлар картайган, бу урын беренче күчтәнтиләрнең зыярат урыны, ә каршы ягы урнашкан урыннары.

1958 нче елны Сараштан ялга кайтып киләбез, көз ае, без Юнус, Вәсил, Фәнзия һәм мин. Ике малай Толбаштан, ә без Карманныкылар. Дәрес соң бетә, без төнгә калдык. Ә ялга кайтырга кирәк. Сакаткыны чыгуга ниндидер тавыш килә, елаган да төсле. Алга карасак, таудан, шул зыярат турыдан инде бер түмгәк килә, карангыда һич шәйләп булмый. Иптәшләр: “ Син курыкмыйсың, алга бас,”- дип мине алга җибәрделәр, үзләре минем арттан киләләр. Борылманы да үттек, теге һаман килә, килеп җиткән идек, - кечкенә генә малай. “Син кем, кая барасың?”- дим, ул дәшми. Шуннан русча сорадым, ул:”Мин Печменнән киләм, юл кайда дип сорады да: “Юлдан читкә чыкма, юл буе барсаң алда авыл,”- дип өйрәттем. Без кузгалдык, ул да кузгалды – юл буенча түгел, урман арасына керде дә китте. Ахыры билгесез.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

**“Плачущий мальчик”**

Между Константиновкой и Амировкой протекают две реки – Чапчельда и Сакатка. При резком повороте от реки Сакатки при подъеме в гору, когда направляешься к Амировке, справа – густой лес, а слева – расстилается поле. Густой лес уже очень старый, деревья одряхлели. Это место первого кладбища константиновцев, а напротив – первое место поселения.

1958 год, я, Юнус, Василь, Фанзия, возвращаемся из Сарашей домой на выходной, осень. Двое мальчишек из Тулбаша, а мы из Кармановки. Уроки закончились поздно и мы припозднились. А возвращаться на выходной домой надо. Прошли Сакатку, послышался какой-то шум, похожий на плач. Посмотрели вперед, с горы напротив кладбища движется какая-то “кочка”, в темноте никак не рассмотреть. Друзья говорят : Ты не боишься, вставай впереди”, - а сами идут за мной. Прошли поворот, “кочка” все приближается, когда подошли, увидели – маленький мальчик. Спрашиваю его по- татарски: “Ты кто, куда идешь?”.- Он не отвечает. Спрашиваю по-русски, он отвечает: “Я иду из Печмени, где дорога?”. Я подсказала и посоветовала : “С дороги не сворачивай, если пойдешь по дороге – впереди село.” Мы двинулись дальше, пошел и он, но не по дороге, а свернул в лес. Чем это закончилось, неизвестно.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Султанай, ул.Ленина,42. 2013 год.

## «Ерынты»

1836нчы елларда Султанайда Гэптелширван хәзрәт яшәгән. Султанай ул вакытта зур гына авыл булган. Габдулширван (русча) 1809 елгы указлы имам-хатип Һәм мөгаллим. 1812нче елдан мәчеттә хезмәт итә, мәдрәсәдә дәрес бирә. (Тукайның бабасы Зиннәтулла хәзрәт Ширван хәзрәттә белем ала). Ширван бөтен округка билгеле була.

Султанай авылы халкын ерынты янына җыеп югары башына халыкны алып бара һәм ерынтыга үзенең посохы белән кадый да: “Бүгеннән бу урыннан чишмә агар,”- ди. Ургылып чишмә атылып чыга, бүген дә бу чишмә изге чишмә дип йөртелә, ялгыш ярында егылсалар, я сүгешенү булса җазасы озак көттерми.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## Овраг

В то время Султанай был большим селом. В 1836 году в Султанае жил преподобный Габделширван. В 1809 году указной имам-хатип второй степени и учитель. В 1812 году он работал в мечети и преподавал в медресе. (Преподобный Зинатулла , дед Габдуллы Тукая, учился у Ширвана). Ширван был известен по всей округе.

Как – то раз он собрал султанаевцев возле оврага, подвел к самому высокому месту, ударил по земле своим посохом и воскликнул: “Сегодня на этом месте забьет родник!”. Из земли с клокотаньем забил родник. И сегодня этот родник считается святым. Если случайно возле него упадут и произнесут нецензурные слова, расплата ждет недолго.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Султанай, ул.Ленина,42. 2013 год.

## “Әтнәш тау хикмәтләре”

Мин үзем Карман авылыннан. Әтиемне 1949-54-нче елларда Толбаш авылына колхозны аякка бастыру өчен председатель итеп җибәрделәр, Карманда өйгә кеше чыгарып куйдылар.

Толбаш авылына без Карманнан җәяү йөри идек. Арада рус авылы Баганалу кул бар иде. Тол елгасы аша чыккач бераз баруга Толбаш җире башлана, юл тау буенча бара, ул икегә бүленә: тау өстеннән атчылар, ә тау астыннан җәяүле дә, атлы да йөри иде. Бу тау Әтнәш тау дип йөртелә. Әтнәш тавы буйдан-буйга кара урманнан торып – шундый матур төз наратлар, агач асты яп- якты һәм төбендә нарат гөмбәсе күп була иде. Әтнәш тавында җиде газизләрнең берсе күмелгән булган. (Күзаллау өчен – хәзерге асфальт һәм Тол күпере Әтнәш тавының башланып киткән җиреннән үтә). Әтнәш тавына килеп тә җитәсең, алдан гүя бер кеше наратларга сугып барамени, 0,5 км. чамасы шулай озатып бара.

Әтиемнең каршысына икенде вакытында капчык аунап килеп төшә, ә капчык эчендә кеше башы, этинең аты өрекеп чак аумыйча кала.

Танып авылының Нараткы очында тегермән бар иде. Тегермәндә торучы Ногман бабай орчык, тарак ясап авыл саен сатып йөри иде. Толбашка тарак - орчык сатарга килгән чагында Әтнәш тавы астында каршысында түгәрәк күл пәйдә була, күлдә аккошлар йөзә, ә күл уртасында кечкенә генә утраучык – анда бик тә чибәр кыз утыра. Кыз бабайны үзенә чакыра башлый. Әле бер нәрсә дә аңламый торган бабай күз алмыйча бер кошларга, бер кызга карый. Исенә килеп китә : “Мине бу бит харап итә “-ди, һәм “Ихлас” сүрәсен укып котыла. Кыз да, күл дә юкка чыга.

Еш кына Тол күперенә якын урында аварияләр булу шуның хикмәте түгелме, уяу булырга кирәктер, мөгаен.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## Тайны горы Этнэш

Я из Кармановки. В 1949-1954 годах моего отца направили в деревню Тулбаш председателем ,поднимать колхоз. Дома в Кармановке поселили квартирантов.

Из Кармановки до Тулбаша мы ходили пешком. На пути была русская деревня (Баганалу кул). После перехода через Тулву через некоторое время начинались земли Тулбаша, дорога шла вдоль горы и раздваивалась: по горе ездили конные, а внизу – конные и пешие. Эту гору называли горой Этнэш. Гора была покрыта красивым стройным сосновым лесом, под соснами светло, часто встречались грузди и боровики. На горе Этнэш был похоронен один из семи Газизов. (Чтобы представить, где начинается гора Этнэш, это там, где сейчас асфальт и мост через реку Тулву). Только подходишь к горе Этнэш, впереди как-будто идет человек и стучит по соснам, так провожает около полукилометра. Как-то раз, во время совершения вечерней молитвы (отец тогда оказался в дороге) к нему прикатился мешок , а в мешке человеческая голова, испуганная лошадь чуть не упала.

Еще один случай. В селе Танып со стоны Наратки была мельница. Мельник Нугман –бабай делал расчески и веретена и продавал их в деревнях. Когда он направлялся по дороге в Тулбаш, чтобы продать свои расчески веретена, вдруг под горой перед ним возникло круглое озеро. В озере плавали лебеди, а посередине небольшой островок, на котором сидела очень красивая девушка. Девушка стала звать бабая к себе. Не понимая , что происходит, дед смотрел то на лебедей, то на девушку. Придя в себя, понял, что это может его погубить. Спасло чтение суры “Ихлас” из Корана. И девушка и озеро исчезли.

Может быть поэтому и сейчас рядом с мостом через Тулву часто случаются аварии, там , наверное, нужно держать ухо востро.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Султанай, ул.Ленина,42. 2013 год.

## «Капкан тавы монахинялары»

Карман авылыннан 15-20 км. ераклыкта Капкан тавы урнашкан. 1956 нчы елда миңа бу тауга сәяхәт белән бару насыйп булды. Ат юлы белән Капкан авылын үтүгә тауга күтәрелә башлыйбыз. Юл тар гына, ике яклап урман, тауга күтәрелүгә тип-тигез аланлык күзгә ташлана. Аланлыкның урта өлешендә 1917нче елга кадәр шунда яшәгән монахиняларның монастырь урыны, ул ап-ак кирпичтән төзелгән, вакыт үтүгә карамастан ак кирпич төсен үзгәртмәгән. Монастырьның бер ягы бик текә ярдан икенче ягы сөзәк таудан тора. Аклар килә башлауга монахинялар алтыннарын сандыкка тутырып текә ярдан түбән ташлыйлар, ә аста елганың башланган җире, сазлык. (Чәпчелдә елгасы).

Гражданнар сугышы вакытында монахинялар яралы кызылармеец солдатын яшереп дәвалыйлар. Моны сизеп калган колчаклылар монахиняларны, кызыл солдатны кулга алалар һәм Сарашка алып киләләр. Сараш авылын үтүгә ике зыярат арасында солдат кача, ләкин аклар аны атып үтерәләр, ул ике зыярат арасында ерынтының калку урынында күмелә. Сарашка кергәндә ул чор өчен куелган һәйкәл ул урында түгел, солдат ике зыярат арада.

Аклар монахиняларны алга таба алып китәләр. Печмень елгасын үтүгә түбәнгә төшә башлыйлар, Султанай белән Сараш чигендә монахиняләр атылып үтерелә һәм күмелә. Соңыннан бу урыннар сөрү җиренә әйләнә, еш кына кеше башлары, сөякләр чыга дип әйтә торганнар иде. Тынгы тапмаган монахинялар еш кына ялгыз юлчыга күренеп китәләр, я ап-ак зур кош булып күтәрелеп очеп китәләр, я кара киенгән кеше булып күренеп алдан баралар да юкка чыгалар, ә менә 1964нче елда Габдрафикъ белән Сарашка барганда Гата хәзрәт оныгы Нәзи абыйны очрадык. Ул Печмень елгасын инде чыккан каршыга килә иде. “Уланнар, монда ак ат йөри иде, күрмәдегезме,-” ди. Габдрафикъ: “Күрмәдек тә, Нәзи абзый,”- дип әйтте.”

Монахинялар Нәзи абыйга ак ат булып күренгәннәрме, әллә Нәзи абый безгә ак бәхетләр теләгәнме, менә бусы бер могҗиза. Без Сарашка загска керергә бара идек. Шулай да Нәзи абыйга бик рәхмәтлемен, авыр туфрагы җинел булсын. Монахинялар да тынычлана төшкәндер, чөнки ул җир инде эшкәртелми, рухлары шат булсын, авыр туфраклары җинел булсын.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## Монахини горы “Капкан”

На растоянии 15-20 километров от Кармановки расположилась гора Капкан. В 1956 году мне довелось побывать на этой горе . По конной дороге после деревни Капкан начался подъем . Дорога узкая, по обе стороны лес, после подъема на гору в глаза бросается совершенно плоская поляна. Посередине поляны до 1917 года располагался монастырь, он был построен из белого кирпича, несмотря на время, кирпич не потерял своей белизны. С одной стороны монастыря - крутой обрыв, с другой – покатый склон. Когда стали приближаться белые, монахини сложили свое золото в сундук и сбросили с кругого обрыва, а внизу исток реки Чапчелде, болотистое место.

Во время гражданской войны монахини скрывали и лечили у себя раненого красноармейца.Узнав об этом, колчаковцы арестовали раненого и монахинь и препроводили их в Сараши. Между двумя кладбищами в Сарашах солдату удалось сбежать, но колчаковцы нагнали и расстрелляли его. Убитый солдат похоронен на самом высоком месте оврага. Возле Сарашей установлен памятник , посвященный гражданской войне, он стоит не на въезде, а на месте, где похоронен солдат.

Белые погнали монахинь дальше, прошли речку Печменку, спустились вниз и на границе между Сарашими и Султанаем расстреляли их и закопали. Позже это место превратилось в пашню, часто во время распашки находили здесь черепа и человеческие кости. Не покаенные души монахинь часто являются одиноким странникам или в виде большой белой птицы или одетого в черное путника, который идет впереди, а потом исчезает. В 1964 году , когда мы с Габдрафиком шли в Сараши , встретили по пути внука Гаты хазрата Нази абыя. Он уже перешел речку Печменку и шел к нам навстречу. Поравнявшись, спросил: “Дети, здесь была белая лошадь, вы не видели?”. Мы ответили, что не видели.

Загадка: то ли Нази абыю монахини привиделись в образе белой лошади, то ли он так пожелал нам счастья, не известно. Мы тогда шли в Сараши в загс, чтобы расписаться. Как бы то ни было, я очень благодарна Нази абыю, пусть земля ему будет пухом. Да и

монахини нашли покой, сейчас эти земли не обрабатываются, никто их не тревожит, пусть упокоятся их души.

Масагутова Гульзихан Газихановна. Султанай, ул.Ленина,42. 2013 год.

**Карагай тау хуҗасы**

Күчтәнти елгасы буенда элек заманда карагай урманы булгандыр. Хәзерге көндә дә эле 5-6 карагай үсә. Шуңа күрә ул тауны “Карагай тау” дип атап йөрткәннәрдер. Бу тау изге тау дип йөртелә, чөнки анда гражданнар сугышы вакытында бик укымышлы мулланың өч кызын атып үтергәннәр дип сөйлиләр. Шәмсекамәр, Шәмсенаһәр, Шамсекаурый исемле бу кызларны шушы тауда җирләгәннәр имеш. Шуңа күрә бу тауда үзеңнең йомышыңны үтәргә, кирәкмәгән нәрсә күмәргә, ташларга ярамый. Тау хуҗасы ачулана (аны тау хуҗасы тота) диләр. Тау хуҗасы рухына аят укытып торырга кирәк диләр.

Сараш авылы, китапхәнәче Тимганова Кәдрия, 2013 ел.

**Хозяин Сосновой горы**

В незапамятные времена вдоль речки Константиновки , возможно, был сосновый лес. И сегодня там растет 5-6 сосен. Видимо поэтому и гору назвали “Сосновой.” Эта гора считается священной: рассказывают, что в годы гражданской войны там расстреляли троих дочерей очень уважаемого и грамотного муллы. Говорят, что здесь и похоронили его дочерей Шамсекамар, Шамсенахар и Шамсекаурый. Поэтому на горе нельзя справлять нужду, закапывать и бросать что попало. Хозяин горы сердится, начинает мстить. В этом случае нужно читать аят из Корана для души хозяина горы.

Записала библиотекарь Сарашевской библиотеки Кадрия Тимганова. 2013 год.

**“Мәмәле чишмәсе”**

Суык Ак чишмәне үтүгә Мәмәле каберлеге күренә, аннан түбәндә Мәмәле чишмә челтерәп агып ята. 1900 еллар терәсендә бу урында Җәмилә исемле апа кое бурасы утырта, һәм бу коедан Мәмәле авылы кешеләре су ала. Еллар үтүгә кое чери-тарала. Чишмә агуын давам итә. Мәмәле кешеләре дә Султанайга күчеп утыра. Моннан 10 еллар чамасы элек Кариев Алмаз чишмәне чистартып, улак ясап матурлап куя. Ильмира чишмә буен бизәкли, чишмә матур төс ала. Авыл халкы чишмә суын алырга бара- суы бик чиста, йомшак, юшкыны юк, чишмәгә акча салу да ырымга керә башлады.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

**Родник “Мамали”**

После холодного Белого родника видно захоронение Мамали, ниже журчит родник Мамали. Где-то в 1900 годах на этом месте женщина по имени Джамиля поставила

колодезный сруб, и из этого родника жители деревни Мамали стали брать воду. Со временем сруб сгнил и развалился, а родник продолжал бить из под земли. Жители той деревни перебрались в Султанай. Лет десять тому назад Кариев Алмаз вычистил родник и установил сток. Ильмира украсила место возле родника, оно стало привлекательным. Сельчане приходят к роднику, берут воду. Вода здесь чистая, мягкая. Стала приживаться традиция благодарить родник – сельчане бросают в родник монеты.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

### Нәзи абый могҗизалары

Гата хәзрәт балаларын да, оныкларын да укыткан, һәрберсе белемле, тәртипле, дөньяви фән белемнәрен тирәнтен өйрәнгәннәр. Нәзине дә хәзрәт белем алу өчен шәһәргә җибәргән, ләкин Касим улы Нәзи мулла булу уеннан кире кайтып күз буарга, яки гипнозга өйрәнгән, бик көчле гипнотезер булган. Район халкы аны хөрмәт тә иткән һәм курка да төшкән. Бервакыт Нәзине дуслары белән төрмәгә япканнар, берничә көн булгач иптәшләреннән:

Чыгасыгыз киләме,- ди икән.

Билгеле, чыгасы килә инде. Шул вакыт Нәзи төрмәгә "су чыгарган", бөтен җирне су баса икән, төрмә ишекләрен ачып чыгарганнар инде. Бусын Азат абый сөйли:

- Ашап-эчеп утырабыз, Нәзи абый килеп керде, тизрәк өстәл янына утырттык, ашатабыз –эчертәбез,- ди.

-Малайлар, су чыгарыйммы ?- ди икән Нәзи абый.

-Әйдә-әйдә ,Нәзи абый!- диләр икән болар.

Әле инде су чыккан, өстәл өстенә менеп басканнар.

-Үрдәк йөздеримме?- ди икән Нәзи.

- Әйдә,- диләр икән.

Инде үрдәкләр дә йөзә.

-Суееммы?- ди икән Нәзи.

-Суй- суй!- диләр икән тегеләр.

-Ярар, аз гына суеем әле,- ди икән Нәзи.

Инде су беткән, кайтырга вакыт җиткән, карасалар, аяк киемнәре киселгән, я башы , я кунычы. Аяк киемне үрдәк итеп йөздергән икән. Бик кызык абый, ике яклы көзге белән бәхет тә әйтә торган булган. Иптәш кыз белән ялга (без Сараштa укыдык, ялга Карманга җәяү кайтабыз) кайтып барабыз. Сараш белән Танып арасында Карабай дигән кул бар, менә шул җирне үтүгә сукмактан бер абый килә (бу 1959нче ел). Фәнзия(иптәш кыз):

-Алла, Нәзи ышпана килә,"-ди.

Аның туганнары Башап түздән булгач ул аны белә икән.

-Нигә куркасың?- дим.

-Ул кешене алдата да.

-Безнең нәрсәне алдата ул ? -дим.

Килеп җитүгә:

-Кызлар, бәхетегезне әйтәм,-ди.

-Абый, без укучылар гына, 5 тиен генә акчабыз бар,- дим.

-Миңа 5 тиен дә җитә, куркмаң,- ди

Фәнзия сөйләшми, артта тора, учка көзгесен куйды да миңа карап :

-Кызым, бик бәхетле буласың, урындагы кешегә чыгарсың, 3 кызың була,-ди

Ә Фәнзиянекен оныттым, барысы да дөрес, тагын да 3 малаең була дисә, курыкыр дип әйтмәгән микән. Әнә шундый могҗизалы абый белән ике тапкыр очраштык. Рухы шат булсын инде.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## Волшебство Нази абыя

Гата хазрат давал образование все детям и внукам, каждый был грамотным, воспитанным, углубленно изучал науки. И Назия хазрат отправил в город на учебу, но Нази Касимович отказался от мысли стать духовником, а обучился гипнозу, чтобы обманывать людей, он был сильным гипнотезером. Население района его и уважало и боялось. Как-то раз Назия с друзьями посадили в тюрьму, через несколько дней он спрашивает у товарищей:

-Выйти хотите?

Конечно, выйти хочется. Тогда Нази "затопил" тюрьму водой, открыли все двери и затворников выпустили.

А это рассказал Азат абый:

-Гуляем, зашел Назий абый, мы поскорее посадили его за стол, угощаем.

- Ребята, хотите устрою потоп?- предлагает Назий абый.

- Давай. Нази абый, давай!- кричат ребята.

Начался "потоп", все забрались на столы.

- Хотите, поплывут утки?- спрашивает Нази.
- Давай-давай!- кричат те.

Теперь плавают утки.

- Зарезать уток?- спрашивает Нази.
- Режь-режь!- кричат они.
- Ладно, немножко зарежу,- говорит Нази.

Вот и "вода ушла". Пришло время расходиться. Смотрят, а обувь порезана: или носок , или голенище. Оказывается, они свою обувь заставляли плавать вместо уток.

Это был очень интересный дядька, двухсторонним зеркалом он умел предсказывать судьбу. Как то раз вместе с подругой пешком возвращаемся домой из Сарашей, мы учились в Сарашах, а жили в Кармановке. Между Сарашами и Таныпом есть овраг, который называют Карабай. Прошли это место, а по тропинке идет мужчина. (Это 1959 год.). Подружка Фанзия:

-Ой, кажется, это Нази шпана идет.

Так как ее родственники из Усть Ашапа, она его знает.

-Чего боишься?- спрашиваю .

-Он людей обманывает.

-Как он может нас обмануть?- говорю я.

Приблизившись, Нази абый говорит:

-Девушки, я вам предскажу судьбу.

-Дяденька, у нас только 5 копеек,- говорю я.

-Мне достаточно и пяти копеек,- отвечает Нази абый.

Фанзия не разговаривает, стоит позади меня. Нази абый кладет свое зеркало на мою ладонь и рассказывает:

- Дочка, будешь очень счастлива, выйдешь замуж за местного, будет три дочери.

Что он нагадал Фанзии, я не помню. Мое же предсказание полностью сбылось, правда, он не сказал,что у меня будет еще три сына, видимо, подумал, что испугаюсь. С таким интересным дядькой я встречалась два раза. Пусть душа его будет покойна.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

## ”Өрәк”

Мин өченче класста укый  идем. Безнен авыл клубы мәчеттә урнашкан иде. Мин дә бер кич мәчеткә  кино карарга киттем. Ә мәчет урында сугыш вакытында аклар һәм кызыллар сугышы булып күп кан коелган диләр. Кино бетмәс борын йокым килеп үзем генә мәчеттән  чыктым. Караңгыда озын буйлы бер “кеше” миннән алда бара башлады. Әнә бит,  Әхмәй бабай да кайтырга булган дип, бабай артыннан йөгерә башладым. Ләкин аның артына җитә алмыйм. Мин йөгерәм, ул кызу гына атлый. Мин өйгә кереп киттем, ә бабай әкрен генә китеп калды. Моны әнигә сөйләдем. Ә үзем калтырыйм, уттай янам. Төн уртасында хәлем авырлашты. Әни күрше Фәтиха әбине чыгып алды һәм мине су белән чайкап алып шул суны мәчет тавына илтеп сипте. Мин шуннан соң гына тынычлап йоклап киткәнмен.

Әни бу күренешне мәчет тау хуҗасы яки Өрәк булгандыр, бездән өмет итүе булгандыр дип юрады.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

## Привидение

Я училась в третьем классе. Сельский клуб располагался в здании мечети. Я как-то вечером  отправилась в мечеть смотреть кино. ( На месте мечети во время войны было пролито много крови и белых и красных). До окончания фильма захотелось спать и я одна отправилась домой. В темноте передо мной  идет высокий“человек”. “Вот ведь, и Ахмай бабай решил уйти домой,”- подумала я и побежала за ним. Но догнать не могу. Я бегу, а он быстро шагает. Я зашла в дом, бабай потихоньку пошел дальше. Рассказала об этом маме. А сама дрожу, горю как в огне. В полночь мне стало совсем плохо. Мама сходила за соседской бабушкой Фатихой, она обмыла меня водой и эту воду вылила на гору у мечети. Только после этого я спокойно заснула.

Случившееся со мной  мама объяснила тем, что или хозяин горы, или привидение что-то от нас хотели.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

## Татара  чишмәсе

Тауавылда шундый исемле чишмә бар, ул Нәсипкул  дип аталган аланда (авылдан 500 м.) җиркендектән башлана. Нигә Татара дигәннән, авылдагы картлар (иң өлкән әбигә 92 яшь):

- Бу сүз борынгы сүздер, татар сүзе түгелдер, без кечкенә  чакта ук шулай дияләрей әниләр,- ди.

Хәзерге Татара таудан төшеп, бакчалар, урамнардан Иске Тол (элек Тол шуннан аккан) күленә килеп кушыла, яңгырлы елларда гына Толга килеп җитә. Чишмәнең озынлыгы 1,5 км., язгыда басуларда кар күп булып, тиз эреп беткәндә, ул бакчаларны, урамнарны баса. Элек ул каян тели, шуннан аккан, авылның үзәк урамыннан бу чишмә аша агач күпер ясаганнар, хәзер күпере юк, урамы шул ук. Бер йортның ишек алдыннан агып, күл булып яткан (Аккүз әби күле дип йөрткәннәр), кайбер елларда урамнардан да

аккан. Хәзер ул күл юк, анда бакчалар. Шушы элек аккан юлын бульдозерлар белән үзгәрткәннәр (ничәнче елда икәнен хәтерләми).

Авылыбызда Татара аша дүрт күпер салынган.

Муртазин Залалтдин Камал улы сөйләвен Барсаева Сәлима, кипатханәче язып алды. Октябрь, 2013 ел.

## Ручей “ Татара”

В Усть Тунторе есть ручей, который называется “Татара”, он начинается в пятистах метрах от деревни с родника на лесной поляне Насипкул.Почему “Татара”, старожилы, самой старой бабушке 92 года, говорят:

-Это слово , наверное, старое, не татарское, еще когда мы были маленькими, родители так называли этот ручей.

Нынешний “Татара” спускается с горы. Течет по огородам, улицам и впадает в озеро Иске Тол (Старая Тулва), только в дождливые годы он достигает Тулвы. Протяженность ручья полтора километра, когда снега много и он резко начинает таять, ручей затопляет огороды и улицы. Раньше он тёк, где придется. На центральной улице деревни через этот ручей построили деревянный мост, сейчас моста нет, улица осталась та же. Было время, когда ручей разливался как озеро перед дверями одного из деревенских домов. Его называли озером белоглазой бабушки. Сейчас этого озера нет, там огороды. В иные годы руслом для него становились деревенские улицы. Старое русло изменили бульдозерами, не помню в каком году.

В деревне через Татару построено четыре моста.

Со слов Муртазина Залалтдина Камаловича записала библиотекарь Усть-Тунторской библиотеки Барсаева Салима.Октябрь, 2013г.

## «Ходай кисәтүе калганнарга сабак»

Әнкәмнең дәү әнисе Сабира исемле. Шулай ук Дилмөхәммәт шикелле нык-таза, эшчән хатын, минем әнкәй шуларга охшаган, ә Габдрафикъ әнисе улы , һәр эшкә уңган кеше иде. Сабирәнең сөйләгәннәре, исемнәр үзгәртелгән – кемгәдер кагыла икән исем, гафу итсеннәр.

Ике семья яшәгән : Мансур – Мансура, Нәҗип- Нәҗибә. Сарашлылар Нәҗибәнең сылулыгына таң калалар икән, андый сылулык кемнән күчкән? Нәҗип үзенең хатыныннан күзен дә алмый икән, аңа ышана, турылыклы булуына инана, шундый хатын белән яшәвенә сөенеп туя алмый. Күршеләр бик тату, кунаклашып, хәл белешеп яши бирәләр. Менә бер вакыт Мансурның күзе Нәҗибәгә төшә, алдына да артына да төшеп үзенеке итә. Авыл халкы бу хәлне сизеп Нәҗипкә әйтә, ләкин Нәҗип бу хәлгә ышанмый: “Сез миннән көнлисез, шуңа шундый сүз әйтәсез, хатынымны каралыйсыз”- ди икән. Еллар шулай гөнаһа белән үтә бара. Менә Нәҗип үлеп китә. Нәҗипне җирләү өчен кабер казырга киләләр (Сарашның Танып ягындагы зыярат). Кабер балчыгын алуга җир астынна еланнар чыга башлый, авызларыннан да, арт якларыннан да елан чыгып бөтен җирне елан баса. Бу каберне күмеп икенче җирдән казый башлауга тагын шул ук хәл кабатлана, кешеләр Танып ягына, ә Танып яктан килүчеләр Сарашка китә алмый, бөтен җир елан белән тула. Мулла чакырып, кабер кырыена басып, укып тора башлый, еланнар чыгуы туктала. Нәҗипне алып киләләр, ләхеткә төшерүгә бөтен еланнар кабергә төшеп китәләр. Халык шакката: “Мулла абый, бу ни хәл, мондый хәл булганы юк иде бит?”- диләр.

Мулла : “ Нәҗип яшәгәндә үз хатынына аллага ышанган кебек ышанды, кеше сүзләрен алга алмады, кешеләргә ышанмады, гөнаһалы хатынын һәрвакыт аклап килде, шуңа күрә ходай тәгаләнең үлгәч җәзасы инде бу,”- ди. Бу вакыйгадан соң Нәҗибә иренә турылыклы булып яшәп үлә. Ә Мансур бүтән хатыннар белән чуалмый. Нәтиҗә ясый белгәннәр нәтиҗә ясар инде. Хыянәтсез тормыш – тормыш бизәге һәм балалар бәхете ул.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

**Божественное предупреждение - урок окружающим**

Бабушку моей свекрови звали Сабира. Такая же, как Дильмухамат, крепкая, работящая женщина, свекровь похожа на них, а Габдрафик мамин сын, любое дело было ему по плечу. Если встретится знакомое имя в рассказе Сабиры, извините, имена в нем изменены.

В селе жили две молодые семьи: Мансур - Мансура и Нажип-Нажиба. Сарашевцы восхищались красотой Нажибы и все гадали, от кого это? Нажип не мог отвести глаз от своей красавицы жены, безоговорочно верил в ее честность и порядочность, был счастлив, что у него такая супруга. Соседи очень дружили, приглашали друг друга в гости, интересовались делами друг друга.

Вот как-то Мансур увлекся соседкой - красавицей и добился ее расположения. Сельчане заметили перемены в отношениях Мансура и Нажибы и сказали об этом Нажипу. Но Нажип не поверил : “Вы мне завидуете, поэтому и говорите что попало, черните мою жену”-, упрекал он сельчан. Годы проходили в грехе.

Нажип умер. Отправились копать могилу (Сарашевское кладбище со стороны Таныпа). Достали землю из могилы, и тут со всех сторон полезли змеи - и спереди и сзади. Все вокруг покрылось змеями. Закопали могилу и начали копать другую – та же картина. Люди не могли пройти ни в Танып, ни в Сараши, всю дорогу заполонили змеи.

Позвали муллу, на краю могилы он начал читать молитву, змеи перестали вылезать. Принесли Нажипа, опустили в могилу и все змеи спустились туда. Народ удивился, люди стали спрашивать у муллы: “Что это такое, подобного никогда не случалось?” Мулла объяснил: “Когда Нажип был жив, он верил своей жене , как Богу, не слушал сельчан, постоянно защищал свою грешную жену. Это божье наказание”.

После этого случая Нажиба изменила свое поведение и умерла верной своему мужу. А Мансур больше не гулял с женщинами.

Кто хочет, тот сделает нужный вывод. Честность украшает жизнь и это счастье для детей.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

**“Шах ара”**

Шермейка янында “Шермеинск” заводы (бакыр заводы) төзелүгә якын- тирәгә бакырга бай таулардан бакыр рудасын атларга төяп Шермейкага озатканнар. Шундый урыннар Башап-Туз авылының Кала тавы астында руда алудан зур тау куышы ясалган, ә Султанай авылының Кала таудан сул ягында зур бакыр ятмасы табылып бу ятманы Шермейкага озатканнар һәм бу Шах ара дип аталып куелган. Руда туры юлдан ташылган, ул юл 7-8 км. чамасы гына дип сөйлиләр.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай авылы. 2013 ел.

**“Шах ара”**

После строительства возле Шермейки “Шермеинского” медеплавильного завода со всех окрестностей, ботатых медной рудой, конные подводы, груженые этой рудой, ходили до Шермейки. Возле Усть Ашапа под горой Кала тау образовалась большая пещера после добычи руды, а слева от Кала тау возле Султаная была найдена большая медная залежь, которую тоже разрабатывали, и руду отправляли в Шермейку. Это место называлось Шах ара. Руда перевозилась короткой прямой дорогой, говорят, протяженностью 7-8 километров.

Масагутова Гульзихан Газихановна, д.Султанай. 2013 год.

**«Шәретдин хәерчесе»**

Султанай, Сөҗән, Бөреҗле аралары туры юлдан бик якын. Атлар, я җәяү йөргәнгә туры юл салынган, еш кына бу юлдан хәзер дә йөрибез. Сугыш елларында һәм сугыштан соңгы елларда ачлыктан өйдән-өйгә кереп хәер сораучылар бар иде. Менә шундый хәер сораучыларның берсе Шәретдин. Ул Султанайда хәер сорап йөргәннән соң Сөҗәнгә юл тоткан. Султанайдан 3-4 км. чамасы юл үткәч Шәрәтдиннең акчасы бардыр дип, һөҗүм иткәннәр һәм үтергәннәр, ул. күмелмәгән. Менә шуннан соң Шәретдин кешеләрне саташтыра башлаган. Султанайдан бер әбинең сыеры югалган, сыер эзләп әби Шәретдин кичүенә хәтле (ул. Кызылъярда) барган. Менә әби сыер тавышы ишетеп кала , ул тавыш килгән якка бара, ләкин сыер юк, тавыш икенче яктан ишетелә, тагын сыер юк, 4-5 сәгать шулай саташтыргач әби янына ак бабай килеп баса да:

- Күп саташтырдым, сыерың биредә юк, кайт инде,- ди икән.

Әби укына- укына кайтып китә.

1982 нче елда Наилә апа шул урында печән чаба, төшке аш якынлаша, шул чак чалгы тапаган тавыш ишетелә (чалгыны үткәрләү өчен я тапыйлар чүкеч белән, я юнгыч белән юналар). Нургали җизнә әле инде чалгы табый бит, дип уйлый икән Наилә апа. Ә Нургали, (минем эткәй була инде) 1980 елның 18нче декабрь көнендә үлгән иде. Наилә апаның эткәйнең үле икәнлеге исенә төшә дә, чалгысын алып кайтып китә һәм бүтән ул урынга печәнгә килми, әнкәй чаба иде.

-Шәретдин котымны алды бүген, бармыйм,- ди икән апа.

1992 нче елларда без Габдрафикъ, Гөлүсә, Инсаф һәм мин шул урынга мүк чыгарырга бардык. Без мүк чыгарабыз, ә Инсаф гөмбә җыеп йөри. Мин эти янына барам әле дип этисе янына китте, ә бераздан этисе безнең янга килде. Инсаф кайда дим, ә ул сезнең янга китте дә ди. Әй мин курыктым, әй курыктым, кычкырып җибәрдем: “ Инсаф”,- дип, ә тавыш килә куе урман эченнән. Тукта!!!- дип кычкырып йөгерә башладым, үзем “Шәретдин, баламны тимә!”- дим. Үзем йөгерәм, ә куе урман эчендә агач ботаклары икегә аерылып юл биреп бара. Мондый да могҗиза булыр икән. Барып җитеп малайга ябыштым да: “ Нишлисең монда,”-дим. “ Кайда монда мәшкә (гомбә)?”- дим. Кулдан ычкындырмыйча кире алып чыктым.

Менә шундый урын бар Кызылъярда. Икенче төрле дә сөйлиләр, Бөреҗледә Шәҗәретдин исемле кешедә хәерче йоклап чыга, ә икенче көнендә ул хәерчене юлда үтерә. Шуңа Шәретдин хәерчесе диләр.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

**Нищий Шаретдин**

Расстояние между Султанаем, Сюзянью и Брюзлями по прямой дороге совсем короткое. Между этими селами проложен конный путь, по нему нередко ездим и сейчас. В военные и послевоенные годы по деревням ходили нищие. Один из них нищий Шаретдин. После того, как собрал подаяние в Султанае, он направился в деревню Сюзянь. Через три-четыре километра от Султаная на него напали и убили, думая, что есть деньги, и похоронили. После этого Шаретдин стал сбивать с толку людей. У одной султанаевской старушки потерялась корова, в ее поисках она дошла до переправы, которая в Кызылъяре.

Старушка слышит коровье мычание, идет на голос, а коровы нет, голос слышен с другой стороны, после 4-5 часов таких мучений перед старушкой вырос белый дед и говорит:

- Долго я сбивал тебя с толку, твоей коровы здесь нет, возвращайся домой.

Старушка, читая молитвы, поспешила домой.

В 1982 году на этом месте Наиля апа косила сено, время близилось к обеду,
слышит звук “направляемой” косы. Для того, чтобы коса была острой, ее или отбивают молотком , или точат точилом. “Кажется, Нургали зять направляет” свою косу”,- подумала Наиля апа. А Нургали (мой свекор) 18 декабря 1980 года умер. Вспомнив об этом, Наиля апа схватила свою косу и убежала, больше на это место она не возвращалась, здесь косила уже моя свекровь.

“Шаретдин меня напугал, больше я туда не пойду,”- объяснила Наиля апа.

В 1992 году Габдрафик, Гулюса , Инсаф и я отправились на это место за мхом. Мы собираем мох, а Инсаф – грибы. “Я пойду к отцу”, - сказал Инсаф и ушел. Через некоторое время пришел муж. “Где Инсаф”,- спрашиваю . “Так он ушел к вам”,- отвечает муж. Вот уж я испугалась, громко крикнула :”Инсаф!!!” А голос слышится из густого леса. Бегаю и кричу: “Остановись!!! Шаретдин, не трогай моего ребенка”. Я бегу, а густые ветви деревьев передо мной расступаются. Дают дорогу. Надо же, какое волшебство?! Добежала до сына , вцепилась в его руку и говорю: “ Что здесь делаешь, где грибы?” И, не отпуская от себя ни на шаг, привела обратно.

Вот такое место есть в Кызылъяре. А еще рассказывают по- другому: нищий переночевал в Брюзлях в доме Шаретдина, а на следующий день этот человек убил его на дороге. Поэтому и называют “нищий Шаретдина”.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

**«Шүрәле баласы»**

Минем әнкәем Нәҗибәнең дәү әтисе Габдрахманов Дилмөхәммәт Сараш кешесе, ә әнкәем дәү әтисе тәрбиясендә үскән. Дилмөхәммәт бәдән гәүдәле, таза, эшчән булып өчне ат тоткан, калган маллары да күп булган, таза хәлле семья булган. Дилмөхәммәт аты белән Нараткы яктагы Сараш урманында (Җирләре шул якта булган, бу 1900нче еллар, аннан да элегрәк булмаса) эшкә китә.Атын черек бер түмгәккә дилбәгесеннән элэктерә, шулвакыт түмгәк авып китә, ә агач төбендә йон белән капланган кап-кара бала ята. Дилмөхәммәт куркып атын алып авылга чаба. Артыннан урман шүрәлесе әй акыра, әй акыра, тавышы Дилмөхәммәтне авылга кадәр озата. Шуннан ул бу урман хуҗасы – Шүрәле баласы булырга тиеш дип куйган. Тукай юкка гына Шүрәле турында язмагындыр.

Масагутова Гөлҗиһан Газихан кызы, Султанай, Ленин урамы, 42нче йөрт. 2013 ел.

**Чертенок**

Дед моей свекрови Нажибы Габдрахманов Дильмухамат, сарашевец, а свекровь воспитывал дед. Он был рослый, здоровый работящий человек, содержал трех лошадей, немало было и другой живности, короче говоря, семья была зажиточная. Как то раз Дильмухамат на своей лошади отправился на работу в сарашевский лес ( со стороны Наратки). (В 1900 годах, если ни раньше, его земля была там.) Прицепил лошадь за вожжи к какой-то гнилой кочке, та упала, а под ней лежит волосатый черный-черный ребенок. Испугавшись, Дильмухамет хватает лошадь и возвращается в деревню. А в след лесной черт так кричит, что крик сопровождает Дильмухамета до самой деревни. После этого он решил, что это чертенок, сын Шурале. Тукай, видимо, не зря писал об этом лесном чудище.

Масагутова Гульзихан Газихановна.С. Султанай, ул.Ленина, 42. 2013 год.

С О Д Е Р Ж А Н И Е


| | |
|---|---|
| **“Бәке чишмәсе”** | **с.2** |
| **“Родник Баки”** | **с.2** |
| **«Бичура»** | **с.2-3** |
| **Домовой** | **с.3** |
| **Бичура** | **с.3** |
| **Домовой** | **с.4** |
| **“Гыйльман чыпчык”** | **с.4** |
| **“Гильман чыпчык”** | **с.4-5** |
| **“Елак малай”** | **с.5** |
| **“Плачущий мальчик”** | **с.5** |
| **“Ерынты”** | **с.6** |
| **Овраг** | **с.6** |
| **“Әтнәш тау хикмәтләре”** | **с.6-7** |
| **Тайны горы Этнэш** | **с.7** |
| **“Капкан тавы монахинялары”** | **с.7-8** |
| **Монахини горы “Капкан”** | **с.8-9** |
| **Карагай тау хуҗасы** | **с.9** |
| **Хозяин Сосновой горы** | **с.9** |
| **“Мәмәле чишмәсе”** | **с.9** |
| **Родник “Мамали”** | **с.9-10** |
| **Нәзи абый могҗизалары** | **с.10-11** |
| **Волшебство Нази абыя** | **с.11** |
| **“Өрәк”** | **с.12** |
| **Привидение** | **с.12-13** |
| **Татара чишмәсе** | **с.13** |
| **Ручей Татара** | **с.13-14** |
| **“Ходай кисәтүе калганнарга сабак”** | **с.14** |
| **Божественное предупреждение – урок окружающим** | **с.14** |
| **“Шах ара”** | **с.15** |
| **“Шах ара”** | **с.15** |
| **“Шәретдин хәерчесе”** | **с.16** |
| **Нищий Шаретдин** | **с.16** |
| **“Шүрәли баласы”** | **с.16** |
| **Чертенок** | **с.17** |


Сост. и перевела заведующая отделом обслуживания центральной библиотеки Л.Х.Шакирзянова.2014 г.